| | |
|---|---|
| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «НИЖНЕЧЕРШИЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ТҮБӘН ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 30 октябрь 2020 ел | № 3 |

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге Уставы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2020 елның 13 ноябренә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2021 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Түбән Чыршылы авыл җирлегенең Түбән Чыршылы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, Бөек Ватан сугышы ветераннары, 1 төркем инвалидлардан, көндезне бүлектә укучы студентлар, хәрби хезмәт узучы гражданнар тыш, алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 400 сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме?:

1.Юлларны кардан чистарту
2. Урамнарны яктыртуны карап тоту.
3.Вак таш җәелгән юлларга ремонт ясау.
4. Агачларны кисү.
« ӘЙЕ»　　　　　　　　«ЮК».

3. Әлеге карарны Түбән Чыршылы авылы, Центральная 105, Центральная 23, Советская, 2, Советская 8, Калмык урамы 22, Югары Чыршылы авылы, Тау урамы, 27, Мордва Ивановкасы, Советская, 13 адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://leninogorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Лениногорск муниципаль районы
«Түбән Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы　　　　Н.Я.Хәйруллина